КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.12.2021 № 315-П

г. Казань

Казан шәһәрендә урнашкан төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территориясе чикләрен раслау турында

2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын һәм аларның территорияләрен махсус җайга салу шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары буларак саклап калу һәм дәүләт саклавы максатларында, боерам:

1. Бу боерыкка 1 нче кушымта нигезендә Казан шәһәре территориясендә урнашкан төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен расларга.

2. Бу боерыкка 2 нче кушымта нигезендә Казан шәһәре территориясендә урнашкан төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимын расларга.


3. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы мәдәни
мирас объектларын саклау
комитетының 2021 елның 6 нчы
декабрендәге № 315-П боерыгына
1 кушымта

Казан шәһәре территориясендә урнашкан региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләре **ЧИКЛӘРЕ**

**1.** Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Мәктәп тыкрыгы урамы буенча урнашкан «1909 – 1922 елларда галим-көнчыгыш белгече Катанов Н.Ф. яшәгән йорт», 1909 – 1922, еллар төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **картасы (схемасы)**




**Шартлы билгеләр:**

| | |
|---|---|
| | - мәдәни мирас объекты территориясе чикләре |
| | - капиталь төзелеш объекты |
| | - җир кишәрлегенең чикләре |
| 16:50:011102 | - кадастр кварталы имзасы |
| :102 | - җир кишәреленең кадастр номеры |
| **1** | - территория чикләренең характерлы ноктасы |

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Мәктәп тыкрыгы урамы буенча урнашкан «1909 – 1922 елларда галим-көнчыгыш белгече Катанов Н.Ф. яшәгән йорт», 1909 – 1922, еллар төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **картографик тасвирламасы**


Төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чиге түбәндәгечә уза:

| Чикне үтү | | Чикне үтү тасвирламасы |
|---|---|---|
| ноктадан | ноктага кадәр | |
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | 2 | 1 нче ноктадан төньяк-көнчыгыш юнәлештә җир кишәрлегенең квартал эчендәге чиге буйлап 2 нче ноктага кадәр; |
| 2 | 3 | 2 нче ноктадан көньяк-көнчыгыш юнәлештә җир кишәрлегенең квартал эчендәге чиге буйлап 3 нче ноктага кадәр; |
| 3 | 4 | 3 нче ноктадан көньяк-көнбатыш юнәлештә Канатовский тыкрыгы буйлап җир кишәрлеге чиге буенча 4 нче ноктага кадәр; |
| 4 | 1 | 4 нче ноктадан төньяк-көнбатыш юнәлештә җир кишәрлегенең квартал эчендәге чиге буйлап 1 нче ноктага кадәр. |

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Мәктәп тыкрыгы урамы буенча урнашкан «1909 – 1922 елларда галим-көнчыгыш белгече Катанов Н.Ф. яшәгән йорт», 1909 – 1922, еллар төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **характерлы нокталары таблицасы**

| Нокта № | Нокталарның МСК-16 тагы координаталары | |
|---|---|---|
| | Х | У |
| 1 | 475569.16 | 1306388.26 |
| 2 | 475585.61 | 1306416.36 |
| 3 | 475559.33 | 1306432.59 |
| 4 | 475541.88 | 1306404.84 |
| 5 | 475542.21 | 1306404.64 |
| 1 | 475569.16 | 1306388.26 |

**2.** Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Нагорная/Тельман урамы буенча урнашкан «Посад диварлары трассировкасы», XVIII гасыр, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре **картасы (схемасы)**




**Шартлы билгеләр:**

| | |
|---|---|
| (red line) | - мәдәни мирас объекты территориясе чикләре |
| (black line) | - капиталь төзелеш объекты |
| (orange line) | - җир кишәрлегенең чикләре |
| 16:50:010322 | - кадастр кварталы имзасы |
| :46 | - җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| 1 | - территория чикләренең характерлы ноктасы таблицасы |

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Нагорная/Тельман урамы буенча урнашкан «Посад диварлары трассировкасы», XVIII гасыр, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре **картографик тасвирламасы**

Төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чиге түбәндәгечә уза:

| Чикне үтү | | Чикне үтү тасвирламасы |
|---|---|---|
| ноктадан | ноктага кадәр | |
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | 2 | 1 нче ноктадан көнчыгыш юнәлештә Тельман урамы буйлап 2 нче ноктага кадәр; |
| 2 | 3 | 2 нче ноктадан көньяк юнәлештә квартал эчендәге чик буйлап 3 нче ноктага кадәр; |
| 3 | 4 | 3 нче ноктадан көнбатыш юнәлештә квартал эчендәге чик буйлап 4 нче ноктага кадәр; |
| 4 | 1 | 4 нче ноктадан төньяк юнәлештә Зоя Космодемьянская урамы буйлап 1 нче ноктага кадәр; |

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Нагорная/Тельман урамы буенча урнашкан «Посад диварлары трассировкасы», XVIII гасыр, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **характерлы нокталары таблицасы**

| № точки | Нокталарның МСК-16 тагы координаталары | |
|---|---|---|
| | X | У |
| 1 | 477074.99 | 1305528.75 |
| 2 | 477070.47 | 1305543.04 |
| 3 | 477013.31 | 1305523.82 |
| 4 | 477018.06 | 1305509.70 |
| 1 | 477074.99 | 1305528.75 |

Татарстан Республикасы
мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының 2021 елның
6 нчы декабрендәге
№ 315-П боерыгына 1 кушымта

Казан шәһәре территориясендә урнашкан төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән **файдалану режимы**

Казан шәһәре территориясендә урнашкан төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрендә түбәндәгеләр **рөхсәт ителә**:

-мәдәни мирас объектының физик сакланышын тәэмин итүгә юнәлдерелгән мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен башкару, шул исәптән консервацияләү, ремонтлау, реставрацияләү, заманча файдалануга яраклаштыру;

-мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү таләпләренә каршы килмәгән һәм мәдәни мирас объектының заманча шартларда эшләвен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган хуҗалык эшчәнлеген алып бару;

- мәдәни мирас объектын сак предметын тәшкил итүче үзенчәлекләрен үзгәрмичә заманча файдалану һәм җайлаштыру;

гамәлдәге капиталь төзелеш объектларын, шулай ук хуҗалык эшчәнлегенең түбәндәге юнәлешләрен күздә тотучы рөхсәт ителгән файдалану төрләрен билгеләп, җир кишәрлекләреннән (капиталь төзелеш объектларын төзүдән һәм капиталь булмаган корылмалар урнаштырудан башка) файдалану:

- торак төзелешенә хезмәт күрсәтү (код 2.7);
- социаль хезмәт күрсәтү (код 3.2);
- сәламәтлек саклау (код 3.4)
- мәгариф һәм агарту (код 3.5)
- мәдәни үсеш (код 3.6)
- иҗтимагый идарә (код 3.8).
- эшлекле идарә (код 4.1.)
- кибетләр (код 4.4)
- банк һәм иминият эшчәнлеге (код 4.5)
- җәмәгать туклануы (код 4.6.)
- кунакханә хезмәте күрсәтү (код 4.7).
- ял (рекреация) (код5.0);
- спорт (код 5.1.)
- тарихи-мәдәни эшчәнлек (код 9.3);

-мәдәни мирас объектының югалган элементларын һәм өлешләрен гамәлдәге сызымнар, обмерлар һәм тарихи аналоглар буенча торгызу;

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, мәдәни мирас объектының бөтенлеген боза торган корылмаларны һәм объектларны, шул исәптән вакытлыларны, җимерү;

гамәлдәге инженерлык инфраструктурасы объектларын (тышкы су белән тәэмин итү, канализация, җылылык белән тәэмин итү, газ белән тәэмин итү, электр белән тәэмин итү, телефонлаштыру һ.б.) капиталь ремонтлау, шулай ук башкарыла торган эшләр (шул исәптән динамик йогынты) мәдәни мирас объектына йогынты ясамау шарты белән инженерлык инфраструктурасының яңа объектларын җир асты юлы белән салу;

-мәдәни мирас объектын саклап калуга, алардан файдалануга һәм аларны популярлаштыруга юнәлдерелгән территорияне төзекләндерү;

- традицион материалларны (кирпеч, таш, гранит һәм башка табигый материалларны, шулай ук табигый материалларны имитацияләүче материалларны) мәйданчыкларны, килү һәм китү юлларын түшәүдә файдалану;

- тарихи мохит элементлары характеристикаларына җавап бирә торган аерым урнаштырылган яктырту җиһазларын куллану;

яшелләндерү: агачларны яшелләндерү, яшел утыртмаларны санитар кисү, яшелләндерүнең яңа элементларын утырту;

-тарихи-шәһәр төзелеше мохитен саклап калу, мемориаль һәм архитектура-ансамбль мөнәсәбәтендә югалган тарихи элементларны (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, аларны торгызу өчен кирәкле җитәрлек фәнни мәгълүматлар булганда) торгызу;

-мәдәни мирас объектының төп фасадында мәгълүмати язмалар һәм билгеләр урнаштыру беренче каттан да югары түгел;

- кулланучылар игътибарына «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 07 февралендәге 2300-1 номерлы Федераль закон таләпләренә туры китерү өчен билгеләнгән тышкы мәгълүмат чараларын (алтакталарны) урнаштыру: эшчәнлек профиле, оешманың фирма исеме, аның урнашкан урыны (адресы) һәм эш режимы, индивидуаль эшкуарны дәүләт теркәве турында һәм аны теркәгән органның исеме турындагы мәгълүмат законнар нигезендә;

- тышкы мәгълүмат чаралары (алтакталар) биеклеге фриз биеклегеннән 2/3 артык булмаска тиеш, катлар тәрәзәләре арасына теге яки бу конструкцияне урнаштыру регламентлаштырыла;

-мәгълүмати конструкцияләрнең киңлеге, декоратив-сәнгать панноларыннан тыш, теге яки бу конструкцияне урнаштыру регламентлана торган простенка киңлегеннән 2/3 дән артмаска тиеш.

Югарыда атап үтелгән барлык эшләр «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә үткәрелә.

Казан шәһәре территориясендә урнашкан төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрендә түбәндәгеләр **тыела**:

-капиталь төзелеш объектларын төзү һәм һәйкәл яисә капиталь төзелеш объектларының ансамбле территориясендәге күләм-пространство характеристикаларын арттыру; мәдәни мирас объектын яисә аның аерым элементларын саклап калу, мәдәни мирас объектының тарихи-шәһәр төзелеше яисә

табигый мохитен саклау эшләреннән тыш, җир, төзелеш, мелиоратив һәм башка эшләр башкару;

- кондиционерларның мәдәни мирас объектының фасадларында һәм түбәсендә, эре габаритлы антенналар һәм инженерлык җиһазларының башка элементларын урнаштыру;

- тышкы реклама чараларын урнаштыру;

- җир өсте ысулы белән инженерлык инфраструктурасы объектларын (тышкы су белән тәэмин итү, канализация, җылылык белән тәэмин итү, газ белән тәэмин итү, электр белән тәэмин итү, телефонлаштыру һ.б.) үткәрү;

- киосклар, павильоннар, лапаслар, кече архитектур формалар урнаштыру, югалганнарны торгызудан тыш;

- динамик йөкләнеш тудыручы технологияләрне (бәрмәле машиналардан куллану, кривошипно-шатунлы механизмнар, чүкечләр һәм бәрмә хәрәкәтнең башка механизмнарын куллану, мәдәни мирас объектына һәм аның әйләнә-тирәсендәге төзелешләргә күпсанлы машиналарны берьюлы куллану;

- мәдәни мирас объекты территориясен теләсә кайсы төрдәге һәм формадагы төзелеш, көнкүреш калдыклары белән чүпләү;

- агачларны кисү, санитар кисүләрдән тыш.